**НКО “Фонд развития Татнета”**
**Адрес:** 420021, г.Казань, ул.Каюма Насыри, 25
**Тел.**: +7 960 045-63-53, **E-mail**: fondtatnet@yandex.ru
**Сайт**: http://tat-i.net

**«Татнетны үстерү фонды»**
**коммерцияле булмаган оешмасы**
һәм
**«Татарстан Язучылар берлеге»**
**иҗтимагый оешмасы**
оештырган бәйге финалистына

№ 43/2 от 18 августа 2021 г.

# ЧАКЫРУ ХАТЫ

Хөрмәтле бәйге финалисты!

Сезне XV дөньякүләм #әдәбимарафон проектында уңышлы катнашып финалга чыгуыгыз белән чын күңелдән котлыйбыз!

Агымдагы елның 27 нче августында Татарстан Республикасында туган телләр һәм халыклар дуслыгы елы һәм Габдулла Тукайның тууына 135 ел тулу уңаеннан Татнетны үстерү фонды тарафыннан Татарстан язучылар берлеге белән берлектә, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе, республикабыз министрлыклары, Фонда ярдәм итәргә теләк белдергән башка юридик һәм физик затлар ярдәме белән Арча муниципаль районында #ӘДӘБИСАБАНТУЕ үткәреләчәк.

Әлеге тантаналы чарага XIV/XV/XVI дөньякүләм #әдәбимарафон проекты финалистлары (tat-i.net/tt/finalistlar-14, tat-i.net/tt/finalistlar-15, tat-i.net/tt/finalistlar-16), II республикакүләм #авылымгүзәллеге проекты финалистлары (tat-i.net/tt/avilim-guzallege-2021-final), V республикакүләм #сәламәтиртә проекты финалистлары (tat-i.net/tt/salamatirta2021) чакырулы.

Финалист буларак, Сезне 27 нче август көнне 10:00 сәгатьтә Арча шәһәренең үзәк стадионында башланып китәчәк #ӘДӘБИСАБАНТУЕ чарасына чакырабыз!

**Мәгълүмат өчен**. #ӘДӘБИСАБАНТУЕның кыскача программасы:

8:00 – 10:00 Кунакларны каршы алу/теркәү, кульяулык/сөлге җыю.

10:00 – 10:30 Ачылу тантанасы. Кунакларны сәламләү.

10:30 – 12:00 Финалистларны бүләкләү тантанасы

12:00 – 15:00 Әдәби көрәш һәм башка әдәби/милли уеннар

13:00 – 14:00 #сәламәтиртә финалы (финал йөгерүе)

15:00 – 19:00 Арча музейларына экскурсияләр

Ихтирам белән,
Татнетны үстерү фонды директоры,
#әдәбимарафон проекты җитәкчесе Р.М. Гатауллин